**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 7 сентябрь № 620

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өстенлекле «Мәгариф» илкүләм проектын гамәлгә ашыру турында» 2006 ел, 17 май, 249 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өстенлекле «Мәгариф» илкүләм проектын гамәлгә ашыру турында» 2006 ел, 17 май, 249 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 29 гыйнвар, 22 нче; 2008 ел, 7 июль, 468 нче; 2008 ел, 18 декабрь, 893 нче; 2009 ел, 22 июнь, 420 нче; 2010 ел, 13 август, 646 нчы; 2011 ел, 4 август, 632 нче; 2012 ел, 7 март, 196 нчы; 2012 ел, 31 май, 457 нче; 2013 ел, 20 август, 580 нче; 2014 ел, 14 февраль, 86 нчы; 2014 ел, 22 май, 344 нче; 2015 ел, 2 февраль, 52 нче, 2015 ел, 15 июль, 514 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының иң яхшы укытучыларын акчалата бүләкләү өчен конкурс нигезендә сайлап алу кагыйдәләрендә:

3.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Укытучыны акчалата бүләкләүгә тәкъдим итү (алга таба – Дәгъвачы), Дәгъвачының әлеге Кагыйдәләргә теркәлгән 5 нче кушымта нигезендәге форма буенча төзелгән язмача ризалыгы белән, белем бирү оешмасының коллегиаль идарә органының (алга таба – Гариза бирүче) әлеге Кагыйдәләргә теркәлгән 1 нче кушымта нигезендәге форма буенча төзелгән тәкъдиме буенча башкарыла.»;

3.3 пунктның җиденче абзацына «документлар исемлеге буенча» сүзләренә кадәр «форма буенча төзелгән» сүзләрен өстәргә;

3.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.10. Конкурска тапшырылган документларга экспертизаны гамәлгә ашыручы эксперт төркеме составы конкурс комиссиясе тарафыннан

формалаштырыла һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән раслана.»;

3.17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.17. Конкурс комиссиясе хуплаган конкурс җиңүчеләре исемлеге агымдагы елга Челтәр графигы белән билгеләнгән вакытларда Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән раслана.»;

3.19 пункт үз көчен югалтуын таныырга;

4.2 пунктта «Совет» сүзен «конкурс комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Кагыйдәләргә 2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлгән);

әлеге Кагыйдәләргә 5 нче кушымта өстәргә (теркәлгән);

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында өстенлекле «Мәгариф» илкүләм проектын гамәлгә ашыру Советы составында:

Совет составыннан Т.З.Ажимовны, И.Х.Аюповны, М.М.Имамовны, А.Р.Фаретдиновны чыгарырга;

Совет составына кертергә:

| | |
|---|---|
| Вафин Эдуард Яфас улын | Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге идарәчесен (килешү буенча) |
| Камалова Эльвира Рафаил кызын | Татарстан Республикасы мәдәният министрының беренче урынбасарын |
| Матюшин Вадим Николаевичны | Түбән Кама муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф идарәсе башлыгын (килешү буенча) |
| Сидоров Игорь Николаевичны | «А.Н.Туполев ис. Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ» югары һөнәри белемнең федераль дәүләт бюджет белем бирү учреждениесенең теоретик һәм гамәли механика һәм математика кафедрасы мөдирен (килешү буенча) |
| Усманов Айрат Нәгыйм улын | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры урынбасарын. |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков